**СОВЕТ
АЛЬДЕРМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422711, РТ, Высокогорский район,
с.Альдермыш, ул.Хабибуллина, 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

422711, ТР Биектау районы,
Әлдермеш авылы,
Хабибуллин ур, 25

**Тел./факс: +7(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru**


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«24» ноябрь 2015 ел** **№ 15**

**"Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге уставын раслау турында"**

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының» Әлдермеш авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында «муниципаль хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында» 2015 елның 5» октябрендәге комиссия бәяләмәсен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 1 пункты, 44 статьясындагы 3 өлеше, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның, Россия Федерациясе законнарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРЭ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Уставын яңа редакциядә кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге башлыгына Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге уставын билгеләнгән тәртиптә теркәүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны Әлдермеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында) Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бүлегендә халыкка җиткерергә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карар кабул ителгән Устав үз көченә кергән көннән алып, Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 9 декабрендә кабул ителгән «Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге уставын кабул итү турында»гы 36 номерлы карарын үз көчен югалткан дип

таныргa.
5. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Авыл җирлеге башлыгы Т.С.Сабиров